ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
КУРАКОВО АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 24 ноябреннән № 2

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлегенең
Кураково авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Кураково авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елда 26250 сум, 2019 елда юлларны ремонтлауга каралган 29358 сум күләмендә үзара салым акчасыннан Кураково авылының Совет урамы буенча һәм Революция урамы буенча юлларның чокырларын ремонтлау өчен вак таш сатып алырга.

2. Енабердино авылы, Клуб урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән әлеге карарны игълан итәргә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Н.Никифоров